КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2023 ел, 22 сентябрь г.Казань № 1175

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының кайбер карарларына үзгәрешләр кертү турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы мәнфәгатьләрендә ачык сервитутлар билгеләү һәм аларны туктату тәртибе турында» 2011 ел, 12 август, 660 нчы карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2017 ел, 19 июнь, 391 нче; 2019 ел, 26 февраль, 127 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган Татарстан Республикасы мәнфәгатьләрендә ачык сервитутлар билгеләү һәм аларны туктату тәртибенә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

2 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2. Гавами сервитут, җир кишәрлеген милекчедән, җир хуҗасыннан, җирдән файдаланучыдан (алга таба – җир кишәрлегенең хокук иясе) алмыйча, аннан чикләнгән файдалану хокукын билгеләү юлы белән Татарстан Республикасы мәнфәгатьләрен тәэмин итү кирәк булган очракларда билгеләнә.»;

3 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3. Гавами сервитут Россия Федерациясе Җир кодексының 23 статьясындагы 4 пунктының 1 – 7 пунктчаларында каралган максатларда билгеләнә.»;

7 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«7. Гавами сервитут билгеләү инициаторлары – федераль башкарма хакимият органнары, республика башкарма хакимият органнары, җирле үзидарә органнары, теләсә нинди оештыру-хокук рәвешендәге һәм милек рәвешендәге оешмалар, индивидуаль эшмәкәрләр, әгәр гавами сервитутны билгеләү аларның эшен һәм тормыш эшчәнлеген тәэмин итү өчен кирәк булса, гражданнар, шулай ук әгәр җир кишәрлегеннән файдалану хокуклары Татарстан Республикасы мәнфәгатьләрендә аннан фактта файдалану нәтиҗәсендә чикләнгән булса, җир кишәрлекләренең хокук ияләре.»;

8 пунктта «җир мөнәсәбәтләре өлкәсендә Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең вәкаләтле органына» сүзләрен «Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгына» сүзләренә алмаштырырга;

10 пунктта:

2 пунктчада «атасының исеме» сүзләреннән соң «(соңгысы – булганда)» сүзләрен өстәргә;

3 пунктчада «атасының исеме» сүзләреннән соң «(соңгысы – булганда)» сүзләрен өстәргә;

11 пункт үз көчен югалткан дип танырга;

12 пунктның 2 пунктчасында «милекчесе, җирдән файдаланучысы яисә җир хуҗасы» сүзләрен «хокук иясе» сүзләренә алмаштырырга, «атасының исеме» сүзләреннән соң «(соңгысы – булганда)» сүзләрен өстәргә;

14 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«14. Гавами сервитут турында белешмә вәкаләтле орган тарафыннан җибәрелә торган документлар буенча «Күчемсез мөлкәтне дәүләт теркәвенә алу турында» 2015 елның 13 июлендәге 218-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә Күчемсез мөлкәтнең бердәм дәүләт реестрына кертелә.»;

15 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«15. Гавами сервитут билгеләү җир кишәрлеген файдалануда җитди кыенлыкларга китергән очракта, аның хокук иясе, Россия Федерациясе Җир кодексында башкасы каралмаган булса, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетыннан тиешле түләү таләп итәргә хокуклы.»;

3 бүлек үз көчен югалткан дип танырга.

2. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Төрләре Россия Федерациясе Хөкүмәте тарафыннан билгеләнгән объектларны дәүләт милкендә яки муниципаль милектә булган җирләрдә яисә җир кишәрлекләрендә, җир кишәрлекләре бирмичә һәм сервитутлар, ачык сервитут билгеләмичә урнаштыру тәртибен һәм шартларын раслау турында» 2015 ел, 5 июнь, 416 нчы карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2017 ел, 19 июнь, 393 нче; 2018 ел, 3 август, 631 нче; 2018 ел, 17 декабрь, 1152 нче; 2020 ел, 30 декабрь, 1227 нче; 2021 ел, 19 июль, 587 нче; 2021 ел, 31 август, 791 нче; 2021 ел, 12 ноябрь, 1065 нче; 2022 ел, 18 гыйнвар, 22 нче; 2022 ел, 14 апрель, 355 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган Төрләре Россия Федерациясе Хөкүмәте тарафыннан билгеләнгән объектларны дәүләт милкендә яки муниципаль милектә булган җирләрдә яисә җир кишәрлекләрендә, җир кишәрлекләре бирмичә һәм сервитутлар, ачык сервитут билгеләмичә урнаштыру тәртибенә һәм шартларына, 4 пунктның дүртенче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итеп, үзгәреш кертергә:

«дәүләт геодезия челтәренең геодезия пунктлары, дәүләт нивелир челтәренең нивелир пунктлары, дәүләт гравиметрия челтәренең гравиметрия пунктлары, шулай ук махсус билгеләнештәге геодезия челтәрләренең геодезия пунктлары, геодезия, межа, кисәтү билгеләре һәм башка билгеләр (мәгълүмат таблосын (стелаларны) һәм флагштокларны кертеп);».

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин